ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МЕТРӘЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МИТРЯЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

*№5* *«22»февраль 2021 ел*

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Метрәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Метрәй авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәреш кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрэй авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 25 февраль № 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру Тәртибенең **20 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пунктчаны өстәп, үзгәреш кертергә:**

«4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр башкару вакыты җиткән бурыч булу.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru сайты буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Метрәй авыл жирлеге**
**Башкарма комитет житәкчесе** **Г.И.Шакирова**